МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

08.05.2020 г.Казань № 289

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2020 елның 2 июнендә 6691 номеры белән теркәлде

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында к а р а р и т ә м:

1. Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган үзгәрешләрне, расларга.
2. Әлеге боерык 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Министр Э.А. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгы боерыгы белән расланды 08.05.2020 ел. № 289

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган үзгәрешләр

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2014 елның 17 ноябрендәге 628 номерлы «Пенсияләре «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә билгеләнгән, Татарстан Республикасында яшәүче, Россия Федерациясенең һәм (яки) Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актлары буенча социаль ярдәм чараларына хокукы булмаган пенсионерларга, 60 һәм 55 яшенә (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җиткән гражданнарга, 2018 елның 31 декабренә күрсәтелгән федераль законнар күздә тоткан пенсия билгеләү шартларына туры килә торган, ләкин 60 һәм 55 яшенә (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җитмәгән гражданнарга юлда йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» боерыгы белән расланган (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.06.2016 ел № 317, 11.07.2016 ел № 395, 28.11.2016 ел № 668, 08.06.2017 ел № 349, 15.05.2018 ел № 367, 24.09.2018 ел № 897, 21.02.2019 ел № 129, 19.04.2019 ел № 285, 10.09.2019 ел № 688, 14.11.2019 ел № 1007, 05.02.2020 ел № 65 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) Пенсияләре «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә билгеләнгән, Россия Федерациясенең һәм (яки) Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актлары буенча социаль ярдәм чараларына хокукы булмаган пенсионерларга, 60 һәм 55 яшенә (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җиткән гражданнарга, 2018 елның 31 декабренә күрсәтелгән федераль законнар күздә тоткан пенсия билгеләү шартларына туры килә торган, ләкин 60 һәм 55 яшенә (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җитмәгән гражданнарга юлда йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (алга таба – Регламент):

2 бүлекнең «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасында:

2.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Юлда йөрү өчен бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү алу өчен банкта яки башка кредит учреждениесендә федераль законнар нигезендә ачылган счетның реквизитлары күрсәтелгән гариза. Гаризаның киңәш ителә торган формасыәлеге Регламентның 1 нче кушымтасында китерелгән.

2. Мөрәҗәгать итүченең гариза биргән айга кадәрге алты ай эчендә булган керемнәре (Россия Федерациясе Пенсия фондында белешмәләр булган түләүләрдән һәм Россия Эчке эшләр министрлыгы, Россия Оборона министрлыгы түләнә торган пенсияләрдән тыш) турында документлар, шул исәптән:

Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә төзелә торган шартнамәләр буенча эшләр өчен түләү;

крестьян (фермер) хуҗалыгы, шул исәптән юридик зат төземичә хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәсендә алынган керемнәрне дә кертеп, эшкуарлык эшчәнлегеннән алынган керемнәр;

барлык дәрәҗәдәге бюджетлардан социаль түләүләр: пенсияләр, компенсация түләүләре (өстәмәләр, өстәмә түләүләр);

пенсионерларны ай саен өстәмә матди тәэмин итү;

дәүләтнеке булмаган пенсия фондларыннан түләнә торган пенсияләрне дә кертеп, ирекле иминләштерү шартларында түләнә торган өстәмә пенсияләр;

отставкага чыккан судьяларны гомер буена ай саен тәэмин итү;

бала карау буенча ялда булган, оешмалар белән наем шартларында хезмәт мөнәсәбәтләрендә торган гражданнарга айлык компенсация түләүләре.

3. Мөрәҗәгать итүченең милкендә булган, хокуклары күчемсез мөлкәтнең Бердәм дәүләт реестрында теркәлмәгән күчемсез мөлкәт объектларына хокук билгели торган документларның күчермәләре.

4. Мөрәҗәгать итүчедә Россия Федерациясе Торак кодексының 51 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында бирелгән исемлектә күрсәтелгән һәм мөрәҗәгать итүче белән законнар нигезендә бергә яшәтми торган хроник авыруның авыр формасы булуын раслаган белешмә.

Документлар һәм белешмәләр мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры тиешле оешмалардан, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада алына.

Законлы вәкилләр (законнарда каралган очракларда) я мөрәҗәгать итүче билгеләгән вәкаләтле затлар өстәмә рәвештә мөрәҗәгать итүче мәнфәгатьләрен тәкъдим итүгә үз вәкаләтләрен раслый торган документларның күчермәләрен тапшыралар.

Документларның күчермәләре законнарда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган очракта, алар төп нөсхәләре белән тапшырыла һәм Үзәк бүлегенең белгече тарафыннан таныклана.

Гариза бирүче мөрәҗәгать иткәндә паспорт яки шәхесне раслаучы башка документ күрсәтә.

Дәүләт хезмәтен алу өчен гариза бланкын гариза бирүче Үзәк бүлегенә шәхси мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Гариза бланкының электрон

формасы Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының рәсми сайтында урнаштырылган.

Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан «Интернет» челтәре, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша электрон документлар рәвешендә тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин. Яшел Үзән шәһәрендә яшәүчеләр гаризаны шулай ук Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте инфоматлары аша җибәрә алалар. Аларның адреслары Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында урнаштырылган.

Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа кушып бирелә торган документларның күчермәләре (шәхесне раслаучы документның күчермәсеннән тыш) Россия Федерациясе законнары нигезендә расланырга тиеш»;

2.6 пунктының җиденче абзацында «Россия Федерациясе Пенсия фондында» сүзләрен «вәкаләтле органда» сүзләренә алмаштырырга;

3 бүлекнең 3.4.2 пунктындагы өченче абзацында «Россия Федерациясе Пенсия фондында» сүзләрен «вәкаләтле органда» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының (07.06.2016 ел № 317, 07.09.2016 ел № 513, 08.06.2017 ел № 349, 23.05.2018 ел № 392, 24.09.2018 ел № 897, 04.02.2019 ел № 77, 14.08.2019 ел № 622, 14.11.2019 ел № 1009 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) 2015 елның 26 гыйнварындагы 47 номерлы «Абонентка даими файдалануга тапшырылган теркәлгән телефон элемтәсе челтәренең абонент линиясе, радио, күмәк антенна өчен түләү буенча чыгымнарны каплауга субсидия билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» боерыгы белән расланган Абонентка даими файдалануга тапшырылган теркәлгән телефон элемтәсе челтәренең абонент линиясе, радио, күмәк антенна өчен түләү буенча чыгымнарны каплауга субсидия билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (алга таба - Регламент):

2 бүлекнең «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасында:

2.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Банкта яисә башка кредит учреждениесендә ачылган шәхси счет реквизитларын күрсәтеп, элемтә хезмәтләренә субсидия билгеләү турында гариза, форма буенча. Гаризаның киңәш ителә торган формасы әлеге Регламентның 1 нче кушымтасында китерелгән.

2. Затның әлеге Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелгән гражданнар категорияләренә каравын раслый торган документларның күчермәләре.

3. Әлеге Регламентның 1.2 пунктының икенче, өченче абзацларында күрсәтелгән затлар мөрәҗәгать итүченең гариза биргән айга кадәрге алты ай эчендә булган керемнәре (Россия Федерациясе Пенсия фондында белешмәләр булган түләүләрдән һәм Россия Эчке эшләр министрлыгы, Россия Оборона министрлыгы түләнә торган пенсияләрдән тыш) турында документлар, шул исәптән:

Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә төзелә торган шартнамәләр буенча эшләр өчен түләү;

крестьян (фермер) хуҗалыгы, шул исәптән юридик зат төземичә хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәсендә алынган керемнәрне дә кертеп, эшкуарлык эшчәнлегеннән алынган керемнәр;

барлык дәрәҗәдәге бюджетлардан социаль түләүләр: пенсияләр, компенсация түләүләре (өстәмәләр, өстәмә түләүләр);

пенсионерларны ай саен өстәмә матди тәэмин итү;

дәүләтнеке булмаган пенсия фондларыннан түләнә торган пенсияләрне дә кертеп, ирекле иминләштерү шартларында түләнә торган өстәмә пенсияләр;

отставкага чыккан судьяларны гомер буена ай саен тәэмин итү;

бала карау буенча ялда булган, оешмалар белән наем шартларында хезмәт мөнәсәбәтләрендә торган гражданнарга айлык компенсация түләүләре.

Законлы вәкилләр (законнарда каралган очракларда) я мөрәҗәгать итүче билгеләгән вәкаләтле затлар өстәмә рәвештә мөрәҗәгать итүче мәнфәгатьләрен тәкъдим итүгә үз вәкаләтләрен раслый торган документларның күчермәләрен тапшыралар.

Документларның күчермәләре законнарда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган очракта, алар төп нөсхәләре белән тапшырыла һәм Үзәк бүлегенең белгече тарафыннан таныклана.

Гариза бирүче мөрәҗәгать иткәндә паспорт яки шәхесне раслаучы башка документ күрсәтә.

Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа кушып бирелә торган документларның күчермәләре (шәхесне раслаучы документның күчермәсеннән тыш) Россия Федерациясе законнары нигезендә расланырга тиеш.

Дәүләт хезмәтен алу өчен гариза бланкын гариза бирүче Үзәк бүлегенә шәхси мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.

Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазь чыганакларда шәхсән яисә почта аша тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.

Гариза һәм документларның күчермәләре электрон документлар рәвешендә Үзәк бүлегенә гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, «Интернет» челтәрен аша да җибәрелергә мөмкин;

2.6 пунктының бишенче абзацында «Россия Федерациясе Пенсия фондында» сүзләрен «вәкаләтле органда» сүзләренә алмаштырырга;

3 бүлекнең 3.4.2 пунктындагы бишенче абзацында «Россия Федерациясе Пенсия фондында» сүзләрен «вәкаләтле органда» сүзләренә алмаштырырга.

3. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының (07.06.2016 ел № 317, 11.07.2016 ел № 401, 08.06.2017 ел № 349, 18.05.2018 ел № 383, 24.09.2018 ел № 897, 04.02.2019 ел № 77, 07.08.2019 ел № 598, 14.11.2019 ел № 1008 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) 2015 елның 26 гыйнварындагы 46 номерлы «Ай саен

бирелә торган акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» боерыгы белән расланган Ай саен бирелә торган акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (алга таба – Регламент):

2 бүлекнең «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасында:

2.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Банкта яисә башка кредит учреждениесендә ачылган шәхси счет реквизитлары күрсәтелгән, әлеге Регламентның 1 нче кушымтасындагы форма буенча төзелгән бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү билгеләү турында гариза, электрон санаучы имза кулланып имзаланырга мөмкин.

2. Затның әлеге Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелгән гражданнар категорияләренә каравын раслый торган документларның күчермәләре.

Әлеге Регламентның 1.2 пунктының дүртенче һәм бишенче абзацларында күрсәтелгән затлар мөрәҗәгать итүченең гариза биргән айга кадәрге алты ай эчендә булган керемнәре (Россия Федерациясе Пенсия фондында белешмәләр булган түләүләрдән һәм Россия Эчке эшләр министрлыгы, Россия Оборона министрлыгы түләнә торган пенсияләрдән тыш) турында документлар, шул исәптән:

Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә төзелә торган шартнамәләр буенча эшләр өчен түләү;

крестьян (фермер) хуҗалыгы, шул исәптән юридик зат төземичә хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәсендә алынган керемнәрне дә кертеп, эшкуарлык эшчәнлегеннән алынган керемнәр;

барлык дәрәҗәдәге бюджетлардан социаль түләүләр: пенсияләр, компенсация түләүләре (өстәмәләр, өстәмә түләүләр);

пенсионерларны ай саен өстәмә матди тәэмин итү;

дәүләтнеке булмаган пенсия фондларыннан түләнә торган пенсияләрне дә кертеп, ирекле иминләштерү шартларында түләнә торган өстәмә пенсияләр;

отставкага чыккан судьяларны гомер буена ай саен тәэмин итү;

бала карау буенча ялда булган, оешмалар белән наем шартларында хезмәт мөнәсәбәтләрендә торган гражданнарга айлык компенсация түләүләре.

Документлар һәм белешмәләр мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры тиешле оешмалардан, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада алына.

Законлы вәкилләр (законнарда каралган очракларда) я мөрәҗәгать итүче билгеләгән вәкаләтле затлар өстәмә рәвештә мөрәҗәгать итүче мәнфәгатьләрен тәкъдим итүгә үз вәкаләтләрен раслый торган документларның күчермәләрен тапшыралар.

Документларның күчермәләре законнарда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган очракта, алар төп нөсхәләре белән тапшырыла һәм Үзәк бүлегенең белгече тарафыннан таныклана.

Гариза бирүче мөрәҗәгать иткәндә паспорт яки шәхесне раслаучы башка документ күрсәтә.

Дәүләт хезмәтен алу өчен гариза бланкын гариза бирүче Үзәк бүлегенә шәхси мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.

Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазь чыганакларда шәхсән яисә почта аша тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин. Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа кушып бирелә торган документларның күчермәләре (шәхесне раслаучы документның күчермәсеннән тыш) Россия Федерациясе законнары нигезендә расланырга тиеш.

Гариза һәм документларның электрон документлар рәвешендә күчермәләре Үзәк бүлегенә гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән Интернет челтәре ярдәмендә җибәрелергә мөмкин, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан Үзәк бүлегенә электрон йөрткечләрдә тапшырылырга мөмкин. Бу очракта гариза гади электрон имза белән имзаланырга тиеш, ә гаризага теркәлә торган документларның күчермәләре 63-ФЗ номерлы Федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы Федераль законның $21^1$ һәм $21^2$ статьялары таләпләре нигезендә законнарда билгеләнгән тәртиптә электрон имза белән таныкланырга тиеш»;

2.6 пунктының дүртенче абзацында «Россия Федерациясе Пенсия фондында» сүзләрен «вәкаләтле органда» сүзләренә алмаштырырга;

3 бүлекнең 3.4.2 пунктындагы бишенче абзацында «Россия Федерациясе Пенсия фондында» сүзләрен «вәкаләтле органда» сүзләренә алмаштырырга.